

Ләмберә районы Кривозерье авылы зур; бvген анда меннән артык кеше яши. Бу авыл халкы хезмәттә дә тырышлар, буш вакытларын да кvнелле vткәрәләр.
Мәсәлән, Мәдәният йортларында, башка торле эшләре белән бергә, аларнын 2012нче елдан алып, теләкләр буенча «Рукоделие» клубы эшләп килә. Аларга милли бизәкләрне кул эшләрендә булдыру бик тә ошый. Чираттагы утырышларында vзенен гомерен киләчәк буын кешеләрен тәрбияләvгә багышлап, туган мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты буенча белем биргән, ана мәхәббәт тәрбияләгән Равилә Исхак кызы Биккинина (рәсемдә сулдан унга), тормышын экономика белән бәйләп, туып-vскән авылы колхозында тырыш экономист булган Равилә Абдулла кызы Шафеева, кырык елга якын Кривозерье авыл Советы секретаре, депутаты булып халкы очен хезмәт иткән Рәмзия Умәр кызы Ямбаева, мәдәният эшендә тәм табып хезмәт иткән Мәдәният йорты директоры Наилә Шайхатдәр кызы Манеева тосле жеплардән әйберләр бәйләп утыралар.

Шундый утырышларда алар бәйлиләр дә, чигәләр дә, тегәләр дә - тагы жаннары нәрсә тели, шул кул эшләре белән шогыльләнәләр. Менә рәсемдә дә кvнел бизәкләренен борын-борыннан чигеп килгән милли бизәкләр тошергән солгеләр, пәрдәләр, ястык тышлары...Алар, хезмәт ветераннары, әле монын белән генә чикләнмичә, «Якташлар» жыр ансамблендә дә катнашып, матур-матур унышларга ирешәләр. Бу утырышта да жырлый-жырлый, якыннарына жылы киемнәр бәйлиләр - тышта кыш бит. Алар:
...Кvгәрчен горлидер баласын уятырга.
Әлдә ярый дусларым бар кvнелне юатырга.

**Н.ХӘЛИЛ**